КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 сентябрь г.Казань № 847

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларында эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр пособие түләү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларында эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр пособие түләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларында эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр пособие түләү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларында эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр пособие түләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 нче пунктның 2.1.2 нче пунктчасында «муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасы» сүзләреннән соң «(алга таба – оешма)» сүзләрен өстәргә;

2.2 нче пунктта «мәдәният, сәнгать һәм кинематография» сүзләрен төшереп калдырырга, «(алга таба – оешма)» сүзләрен «(алга таба – өчьяклы килешү)» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.5 – 2.9 нчы пунктлар өстәргә:

«2.5. Бер тапкыр бирелә торган пособие яшь белгечләргә эшкә урнашу датасыннан алып өч ел дәвамында биләгән вазыйфасында өзлексез эшләүдән соң бирелә.

Яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган пособие түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар оешма боерыгы белән раслана.

Яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган пособие түләү түбәндәге чорга озайтыла:

Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хезмәт итү яки альтернатив граждан хезмәтенә җибәрү;

йөклелек һәм бала табу буенча ял, өч яше тулганга кадәр бала карау буенча ял;

көндезге формада аспирантурада уку.

Әгәр дә яшь белгеч хезмәт мөнәсәбәтләрен Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш хезмәте яки альтернатив граждан хезмәте, йөклелек һәм бала табу буенча ял, өч яше тулганга кадәр бала карау буенча ял, аспирантурада көндезге формада уку тәмамланган көннән 60 көннән дә соңга калмыйча рәсмиләштерсә, бер тапкыр бирелә торган пособие түләү озайтыла.

2.6. Бер тапкыр бирелә торган пособие алу өчен билгеләнгән эшкә урнашу вакытлары үтүнең җитди сәбәпләренә документлар белән расланган вакытлыча эшкә сәләтле булмау карый. Әгәр дә яшь белгеч хезмәт мөнәсәбәтләрен вакытлыча эшкә сәләтле булмау беткән көннән 60 көннән дә соңга калмыйча рәсмиләштергән очракта, бер тапкыр бирелә торган пособие саклана.

2.7. Яшь белгеч башка оешмага шундый ук вазыйфага күчкәндә, эштә иң күбе 30 көн ял алу рөхсәт ителә.

2.8 Санын яки штатын кыскартуга бәйле рәвештә, яшь белгечне эштән азат иткәндә, алга таба башка оешмага шундый ук вазыйфага эшкә урнашканда иң күбе 60 көн ял алу рөхсәт ителә.

2.9. Яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган пособие төп вазыйфасы һәм бу яшь белгеч тарафыннан берьюлы ике эштә эшләү шартларында гамәлгә ашырыла торган эш вазыйфасы буенча билгеләнә.»;

4.1 нче пунктта «25 декабренә» сүзләрен «1 ноябренә» сүзләренә алыштырырга;

4.1 нче пунктның 4.1.2 нче пунктчасындагы сигезенче абзацны төшереп калдырырга;

4.1 нче пунктның 4.1.2 нче пунктчасындагы унынчы абзацта «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасы яки муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасы турында» сүзләрен «оешма турында» сүзләренә алыштырырга;

5.4 нче пунктта «бер тапкыр пособие бирү турында өчьяклы килешү» сүзләрен «өчьяклы килешү» сүзләренә алыштырырга;

6.2 нче пунктта «биш көн» сүзләрен – «30 көн» сүзләренә, «Министрлыкның яшь белгечкә бер тапкыр пособие түләү турындагы боерыгы чыккан» сүзләрен «өчьяклы килешү төзегән» сүзләренә алыштырырга;

6.7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.7. Бер тапкыр бирелә торган пособие түбәндәге очракларда кире кайтарылмый:

а) оешма белән хезмәт шартнамәсе туктатылган көннән 30 көн эчендә башка оешмага кимендә өч елга (суммар) эшкә урнашканда;

б) билгеле бер ташламалар һәм өстенлекләр бирү законнар белән бәйле булган түбәндәге сәбәпләр буенча хезмәткәрнең инициативасы белән эштән киткәндә:

ире (хатыны) эшкә яки хезмәт итү өчен башка җиргә (шул исәптән чит илгә) күчерелү, әгәр дә яшь белгечкә әлеге җирлектә эш тәкъдим ителә алмаса;

медицина бәяләмәсе нигезендә бу җирлектә эшне дәвам итүгә яки яшәүгә комачаулый торган авыру;

I яки II төркем инвалид дип танылу;

гаиләнең авырый торган әгъзаларын (медицина бәяләмәсе булганда) яки инвалид баланы карарга кирәк булу;

сәнгать өлкәсендә белем бирү программалары буенча көндезге уку формасы буенча югары белем бирүче мәгариф оешмасына кабул ителү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин